Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты

Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАРЫ

«14» июнь, 2023 ел № 9

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге уставы, Питрәч муниципаль районы башлыгының 2023 елның 14 июнендәге х-555 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 223 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов